СОВЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.03.2019 ел № 103

**Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыру планына үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Югары Субаш авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору чараларын тормышка ашыруга комплекслы якын килүне тәэмин итү максатларында Югары Субаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Югары Субаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 18 мартындагы 148 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы чараларын тормышка ашыру планына үзгәрешләр кертергә.

1.1 әлеге карарның 2 пунктында «2020» санын «2021» гә алмаштырырга;

1.2. «Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә «2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыру планы»на 1 нче кушымта нигезендә түбәндәге пунктлар өстәргә;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы Р.Б. Вафинга йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы: Р.Б.Вафин

Югары Субаш авыл җирлеге
башкарма комитетының
2019 елның 20 мартындагы
103 номерлы карарына
кушымта

«2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру » муниципаль программасы чараларын Югары Субаш авыл җирлеге территориясендә гамәлгә ашыру планы

| № п/п | Чаралар | Җаваплы башкаручылар | үтәлү вакыты |
|---|---|---|---|
| | 1. Хокукый һәм оештыру чараларын тәэмин итү, коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән | | |
| 1.6. | Коррупциягә каршы тору буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектларын эшләү | Югары Субаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 2015-2021 еллар. |
| 1.7. | Норматив хокукый актларда ачыкланган коррупцион факторларны бетерү буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу эше | Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы | 2015-2021 еллар. |
| 1.8. | Муниципаль контроль функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны куллану мониторингы үткәрү | Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы | 2015-2021 еллар. |
| 1.9. | Коррупциягә каршы тору өлкәсендә закон актларын үтәүне оештыру, коррупциячел үз-үзеңне тоту мөмкинлеген кыенлаштыра торган һәм коррупция дәрәҗәсен киметүне тәэмин итә торган шартлар тудыру | Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы | 2015-2021 еллар. |
| | 2. Муниципаль хезмәт үтүгә бәйле чикләүләрне һәм тыюларны үтәүне контрольдә тоту механизмын камилләштерү | | |
| 2.7. | Югары Субаш авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның һәм Югары Субаш авыл җирлеге муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең ( алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларның, чикләүләрнең һәм таләпләрнең , шул исәптән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чараларның үтәлешен, шулай ук күрсәтелгән затларны аларны үтәмәгән очракта җаваплылыкка тартуны контрольдә тоту | Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы, | 2015-2021 еллар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.8. | Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чараларны, шул исәптән бүләкләр алуга кагылышлы чикләүләрне, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яки) җайга салу чараларын тормышка ашыру | Югары Субаш авыл җирлегендә кадрлар эше алып бару өчен җаваплы зат | 2015-2021 еллар. |
| 2.9. | Югары Субаш авыл җирлеге администрациясенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан Югары Субаш авыл җирлеге администрациясе муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын үтәүне тәэмин итү | Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы, | 2015-2021 еллар. |
| | 2. Товарлар, эшләр сатып алу өлкәсендә коррупциягә каршы тору, муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен хезмәтләр күрсәтү, муниципаль милекне куллану тәртибен камилләштерү | | |
| 3.1. | "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүне контрольдә тоту | Югары Субаш авыл җирлеге баш хисапчысы | 2015-2021 еллар |
| 3.2. | Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның үтәлешен финанс контролен һәм күзәтчелеген тәэмин итү | Югары Субаш авыл җирлеге баш хисапчысы | 2015-2021 еллар |
| 3.3. | Югары Субаш авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алганда бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану мониторингы | Югары Субаш авыл җирлеге баш хисапчысы | 2015-2021 еллар |
| 3.4. | Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасының рәсми сайтында муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру | Югары Субаш авыл җирлеге баш хисапчысы | 2015-2021 еллар |
| 3.5. | Заказларны урнаштыру, сатып алулар һәм башка конкурент процедураларны гамәлгә ашыру өлкәсендә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыру өлкәсендә хокукый актлар проектларын эшләү | Югары Субаш авыл җирлеге баш хисапчысы | 2015-2021 еллар |
| 3.6. | Муниципаль милектәге мөлкәтне исәпкә алуны оештыру һәм алып бару. Муниципаль милекнең сакланышын һәм кулланылышын контрольдә тоту. | Югары Субаш авыл җирлеге баш хисапчысы | 2015-2021 еллар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.7. | Массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Югары Субаш авыл җирлеге администрациясенең рәсми сайтында мәгълүмат урнаштыру: | Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасы ( килешү буенча), Югары Субаш авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе , Контроль-хисап палатасы (килешү буенча) | 2015-2021 еллар |
| 4. Эшчәнлекнең ачыклыгын һәм үтемлелеген тәэмин итү | | | |
| 4.1. | Югары Субаш авыл җирлеге хакимиятенең рәсми сайтында авыл җирлеге хакимияте эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыруның вакытында һәм тулылыгын тәэмин итү | Югары Субаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 2015-2021 еллар |
| 4.2. | Югары Субаш авыл җирлеге хакимияте муниципаль хезмәткәрләренең гражданнар һәм оешмалар белән эшләүләрен һәм коррупцион хокук бозулар фактлары турында мәгълүмат алуны тәэмин итү | Югары Субаш авыл җирлегендә кадрлар эше алып бару өчен җаваплы зат | 2015-2021 еллар |
| 4.3. | Югары Субаш авыл җирлеге администрациясендә коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча гражданнарны кабул итү | Югары Субаш Авыл Җирлеге Башлыгы | 2015-2021 еллар |
| 5. Коррупциягә каршы тору чараларын оештыру ягыннан тәэмин итү | | | |
| 5.2. | Авыл җирлеге хакимиятенең рәсми сайтына телефон аша кергән гражданнарның коррупция фактлары турында белешмәләре булу-булмауга массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләрне анализлау | Югары Субаш авыл җирлегендә кадрлар эше алып бару өчен җаваплы зат | 2015-2021 еллар |

Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы: Р.Б.Вафин